МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ № 222/о БОЕРЫК

«14» 12 2016

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаларын үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләрен раслау хакында

2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» № 79-ФЗ Федераль законның 12 статьясы, 2003 елның 16 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаларын үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата теркәлеп килүче квалификация таләпләрен расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының
20 16 елның «14» 12
№ 222/о боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазифаларын үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре**

| Дәүләт хезмәте вазифалары категориясе | Дәүләт хезмәте вазифалары төркемнәре | Квалификация таләпләре |
|---|---|---|
| Җитәкчеләр | Төп –<br>эшләр белән идарә итүче, идарәләрнең башлыклары, турыдан-туры буйсынучы бүлекләр башлыклары | Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, тиешле вазифаи бурычларны башкаруга карата кулланыла торган Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм әмернамәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм әмернамәләрен, коррупциягә каршы көрәш турында законнарны, Татарстан Республикасы Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) боерыкларын һәм әмернамәләрен, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә), идарәлек турында нигезләмәне, сектор турындагы нигезләмәне, вазифаи регламентны белү.<br>Министрлыкның структур бүлекчәсе белән җитәкчелек итү күнекмәләре, проектларны эшләү һәм норматив-хокукый актларны куллану, программаларны эшләү һәм проектлар белән идарә итү, квалификацияне һәм һөнәри белемнәр дәрәҗәсен системалы рәвештә үстерү күнекмәләре;<br>стратегик максатларга ирешү өчен кирәкле тематика бурычларын билгели, билгеле бер гамәлләр планын эшли белү;<br>идарәлек карарларын оператив рәвештә кабул итә һәм тормышка ашыра, эшне контрольдә тота һәм бүлекчә эшчәнлеге нәтиҗәләренә анализ ясый белү;<br>хезмәт документлары белән эшләү, эш кәгазьләрен әзерләү күнекмәләренә, халык алдында чыгышлар ясау, эшлекле сөйләшүләр алып бару, шулай ук заманча оргтехника һәм программа продуктлары белән эшли белү күнекмәләренә ия булу;<br>буйсынучы затларның шәхесара мөнәсәбәтләре һәм максат куючанлыгы, аларны нәтиҗәләргә ирешүгә стимуллаштыру һәм аларга вәкаләтләр бүлеп бирү алымнарына ия булу, хезмәттәшләр белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итә, шәхесара каршылыкларны туктата белү |
| | Әйдәп баручы –<br>идарә башлыгы урынбасары, турыдан-туры буйсынучы бүлек башлыгы урынбасары, сектор җитәкчесе | |
| Ярдәмчеләр | Әйдәп баручы | Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, тиешле вазифаи бурычларны башкаруга карата кулланыла торган |

| | | |
|---|---|---|
| | | Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм әмернамәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм әмернамәләрен, коррупциягә каршы көрәш турында законнарны, Министрлык боерыкларын һәм әмернамәләрен, Министрлык турында нигезләмәне, вазифаи регламентны белү.<br>Җитәкче билгеләгән эшчәнлек өлкәсендә эшләү, куелган бурычларның үтәлешен тәэмин итү, хезмәт эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, идарәлек караларын оператив рәвештә тормышка ашыру, эшчәнлек юнәлеше буенча мәгълүматны системага салу, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән хезмәттәшлек оештыру, эшлекле сөйләшүләр алып бару, заманча оргтехникадан һәм программа продуктларыннан файдалану, квалификацияне һәм һөнәри белемнәр дәрәҗәсен системалы рәвештә үстерү, хезмәт документларын әзерләү күнекмәләре |
| Белгечләр | Әйдәп баручы –<br>идарә составында бүлек башлыгы, идарә составында бүлек башлыгы урынбасары | Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, тиешле вазифаи бурычларны башкаруга карата кулланыла торган Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм әмернамәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм әмернамәләрен, коррупциягә каршы көрәш турында законнарны, Министрлык боерыкларын һәм әмернамәләрен, Министрлык турында нигезләмәне, бүлек турында нигезләмәне, вазифаи регламентны белү.<br>Министрлыкның структур бүлекчәсенә җитәкчелек итү, проектларны эшләү һәм норматив-хокукый актларны куллану, программаларны эшләү һәм проектлар белән идарә итү күнекмәләре<br>стратегик максатларга ирешү өчен кирәкле тематика бурычларын билгели, билгеле бер гамәлләр планын эшли белү;<br>идарәлек карарларын оператив рәвештә кабул итә һәм тормышка ашыра, процессларны контрольдә тота һәм бүлекчә эшчәнлеге нәтиҗәләренә анализ ясый белү;<br>хезмәт документлары белән эшләү, эш кәгазьләрен әзерләү, заманча оргтехникадан һәм программа продуктларыннан файдалану күнекмәләренә ия булу;<br>конструктив тәнкыйтькә, халык алдында чыгышлар ясау, эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләренә ия булу;<br>буйсынучы затларның шәхесара мөнәсәбәтләре һәм максат куючанлыгы, аларны нәтиҗәләргә ирешүгә стимуллаштыру һәм аларга вәкаләтләр бүлеп бирү алымнарына ия булу, хезмәттәшләр белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итә, шәхесара каршылыкларны туктата белү |
| | Әйдәп баручы –<br>әйдәп баручы киңәшче, әйдәр баручы консультант | Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, тиешле вазифаи бурычларны башкаруга карата кулланыла торган Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм әмернамәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм әмернамәләрен, коррупциягә каршы көрәш турында законнарны, Министрлык боерыкларын һәм әмернамәләрен, Министрлык турында нигезләмәне, бүлек турында нигезләмәне, вазифаи регламентны белү.<br>Җитәкче билгеләгән эшчәнлек өлкәсендә эшләү, куелган бурычларның үтәлешен тәэмин итү, хезмәт эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, идарәлек караларын оператив рәвештә тормышка ашыру, эшчәнлек |

| | | |
|---|---|---|
| | | юнәлеше буенча мәгълүматны системага салу, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән хезмәттәшлек оештыру, эшлекле сөйләшүләр алып бару, заманча оргтехникадан һәм программа продуктларыннан файдалану, квалификацияне һәм һөнәри белемнәр дәрәҗәсен системалы рәвештә үстерү, хезмәт документларын әзерләү күнекмәләре |
| Тәэмин итүче белгечләр | Әйдәп баручы – әйдәп баручы белгеч<br>Өлкән – 1 разрядлы өлкән белгеч | Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, тиешле вазифаи бурычларны башкаруга карата кулланыла торган Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указларын һәм әмернамәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм әмернамәләрен, коррупциягә каршы көрәш турында законнарны, Министрлык боерыкларын һәм әмернамәләрен, Министрлык турында нигезләмәне, бүлек турында нигезләмәне, вазифаи регламентны белү.<br>Йөкләнгән өлкәдә Министрлык эшчәнлеген оештыру, мәгълүмат, документ, финанс-икътисад, хуҗалык ягыннан һәм башкача тәэмин итү буенча бурычлар һәм вазифалар үтәлешен тәэмин итү, идарәлек карарларын тормышка ашыру, башкарма дисциплина, хезмәт эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, заманча оргтехникадан һәм программа продуктларыннан файдалану, квалификацияне һәм һөнәри белемнәр дәрәҗәсен системалы рәвештә үстерү, хезмәт документларын әзерләү күнекмәләре |